ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
16.10.2024

**К А Р А Р**
№ 957

# 2025 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елга расларга:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымтада бирелгән норматив чыгымнарны;

балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,75 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Ф.Хәкимуллин

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
башкарма комитетының 2024
елның 16 октябре 957нче
номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә**

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (1 укучыга елга сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | укытуның өчьеллык срогы | укытуның дүртьеллык срогы | укытуның бишьеллык срогы | укытуның җидееллык срогы | иртә һөнәри ориентация |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 83 699 | 95 607 | 122 722 |
| Рәсем сәнгате | авыл җирлеге | | 44 232 | | 39 296 | 94 291 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 93 401 | 76 913 | 281 919 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 39 265 | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 85 893 | 82 475 | 132 470 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 129 245 | | 123 915 | | 203 145 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 66 606 | | 62 016 | 61 926 | 93 302 |